**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 14 апрелендәге 1261 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 4824 номерлы карары белән расланган Павлюхин һәм Ротор урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 4824 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 июнендәге 1978 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Павлюхин һәм Ротор урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә

территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән үзгәрешләр кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 29 маендагы 1503 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 4367 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 899 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 3448 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 4367 номерлы, 2023 елның 29 маендагы 1503 номерлы һәм 2024 елның 31 гыйнварындагы 347 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4122 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә раслау юлы белән үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 апрелендәге
1261 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 4824 номерлы карары белән расланган Павлюхин һәм Ротор урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, эшләп килүче һәм планлаштырыла торган планлаштыру структурасы элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымында, «Яңа төзелешнең хезмәт күрсәтү объектлары» дигән 2 номерлы таблицасында генплан буенча билгеләнгән «Ш-1» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ш-1 | 88 номерлы гомуми белем бирү мәктәбенең спорт комплексы | - | - | 1 | 1,31» |

2. «Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында, торак, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары һәм мондый объектларның эшләве һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларының характеристикалары турында» дигән III бүлекнең «Яңа төзелешнең хезмәт күрсәтү объектлары» дигән 2 нче таблицасындагы 2 пунктта генплан буенча «Ш-1» тамгасы булган юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ш-1 | 88 номерлы гомуми белем бирү мәктәбенең спорт комплексы | - | - | 1 | 1,31» |

---

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 апрелендәге
1261 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, башка капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә.

2. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны, элемтә линияләрен, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын билгели торган линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә.

3. «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» дип аталган IV бүлектә:

3.1. «Яңа торак төзелеше характеристикалары» дип аталган 3 пунктта:

3.1.1. таблицада 2.2 номерлы участоктагы җир өсте катлары санын «12 гә кадәр» дип укырга;

3.1.2. 7 нче абзацта «2.4 номер» сүзләреннән соң «һәм 2.2 номер» сүзләрен өстәргә;

3.2. «Социаль-көнкүреш һәм мәдәни төзелеш характеристикасы» дип аталган 4 пунктта таблицага түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| Генплан буенча билгеләү | Урам | Үлчәү берәмлеге | Проект буенча сыйдырышлылыгы | Объектлар саны | Җир кишәрлеге мәйданы (га) |
|---|---|---|---|---|---|
| **Гомуми белем бирү оешмалары** | | | | | |
| «Ш-1 | 600 урынга исәпләнгән янкорма төзеп, 88 номерлы гомуми белем бирү мәктәбе (реконструкцияләү) | Урыннар | 1200 | 1 | 1,5» |

3.3. «Инженерлык-техник тәэмин итү системасын үстерү характеристикасы» дип аталган 6 пунктта:

3.3.1. «Су белән тәэмин итү» дип аталган 6.1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«88 номерлы урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасы янкормасының су белән тәэмин итү системасына йөкләнеш тәүлегенә 117,74 куб.м тәшкил итә.

«88 номерлы урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасы янкормасының су белән тәэмин ителешен Ботаника урамындагы Ø300 мм диаметрлы эшләп килүче сууткәргеч буенча башкарырга тәкъдим ителә. Проект буенча 27 м озынлыкта Ø110 мм су үткәргеч челтәре төзү карала»;

Котельный бинасын сүтү сәбәпле проектта су чыгару насос станциясен күчерү һәм су белән тәэмин итү челтәрләрен күчерү тәкъдим ителә»;

3.3.2. «Су чыгару» дип аталган 6.2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«88 номерлы урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасы янкормасының су чыгару системасына йөкләнеш тәүлегенә 117,74 куб.м тәшкил итә.

Юынтык суларны Бөгелмә урамындагы Ø800 мм канализация коллекторына чыгарырга тәкъдим ителә. Проектта Ø225 мм диаметрлы 140 м озынлыктагы су чыгару челтәре төзү күздә тотыла»;

3.3.3. «Явым-төшем канализациясе» дип аталган 6.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Янкорма территориясеннән чыгарыла торган яңгыр суларын Ботаника урамындагы 14 нче йорт тирәсендә урнашкан эшләп килүче яңгыр канализациясе челтәрләренә чыгарырга тәкъдим ителә»;

3.3.4. «Җылылык белән тәэмин итү» дип аталган 6.4 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«88 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасы янкормасының җылыту системасына йөкләнеш 2,881 Гкал/сәг. тәшкил итә.

«88 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасының проектлана торган янкормасын җылылык белән тәэмин итү 2Ø325 мм җылылык белән тәэмин итү челтәреннән башкарыла (әлеге челтәрләр «Татэнерго» АҖ филиалы – Казан җылылык челтәрләре мәгълүматлары нигезендә җир астына күчерелгәннән соң)»;

3.3.5. «Электр белән тәэмин итү» дип аталган 6.5 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«88 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе бинасы янкормасының электр белән тәэмин итү системасына йөкләнеш 150,0 кВт тәшкил итә.

Янкорманы электр белән тәэмин итү гамәлдәге ТП-395 тән, эшләп килүче электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырып башкарыла.

88 номерлы мәктәп янкормасын төзү зонасына керә торган 180 м озынлыктагы участокны сүтеп, 0,4 кВ электр белән тәэмин итү кабель линиясен реконструкцияләү»;

3.3.6. «Газ белән тәэмин итү» дип аталган 6.6 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«88 номерлы мәктәп янкормасын төзү зонасына эләгә торган 315 м озынлыктагы түбән басымлы Ø273 мм газүткәргечне чыгару»;


3.3.7. «Аз токлы челтәрләр» дип аталган 6.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:


«88 номерлы мәктәпнең янкормасын төзү зонасына эләгә торган 63 м озынлыктагы участокны чыгарып, элемтә челтәрен реконструкцияләү».

---

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа планировки территории с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, иных объектов капитального строительства






## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ


- Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- красная линия — Действующая красная линия улично-дорожной сети
- технический коридор инженерных коммуникаций и сооружений — Граница планируемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- технический коридор инженерных коммуникаций и сооружений — Граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- 6 — Зона размещения общеобразовательных организаций (планируемая реконструкция)
- Существующая сохраняемая застройка
- Существующая застройка, подлежащая сносу с целью освобождения территории в установленном законом порядке
- 1 — Порядковый номер зоны размещения
- 6 — Вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 1.5 — Площадь зоны размещения, га
- 3.5.1 — Коды видов разрешенного использования
- н.у — Максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м)
- н.у — Максимальная этажность (этаж)
- 16:50:070116:40 — граница земельного участка

## Характеристика социально-бытового и культурного строительства

| Обозначение по генплану | Наименование | Единица измерения | Вместимость по проекту | Количество объектов | Площадь земельного участка (га) |
|---|---|---|---|---|---|
| **Общеобразовательные организации** | | | | | |
| Ш-1 | Общеобразовательная школа ООШ №88 со строительством пристроя на 600 мест (реконструкция) | Мест | 1200 | 1 | 1,5 |

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, линий связи, объекты инженерной и транспортной инфраструктур




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- Действующая красная линия улично-дорожной сети
- Граница планируемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- Граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- Граница земельного участка
- Граница планируемого размещения объектов капитального строительства

### Линии связи и объекты инженерной инфраструктуры, планируемые к размещению:

- Г1 — сети газоснабжения с рабочим давлением до 0,005МПа включительно
- демонтируемые инженерные сети
- 2Т — сети теплоснабжения
- В1 — сети водоснабжения
- В1 — сети водоснабжения утвержденного ППТ №3320 от 19.09.2019г.
- К1 — сети хозяйственно-бытовой канализации
- К1 — сети хозяйственно-бытовой канализации утвержденного ППТ №3320 от 19.09
- К2 — сети дождевой канализации
- Сс — сети связи
- V1 — кабельные линии электроснабжения 0,4кВ
- Планируемая насосная станция
- Насосная станция планируемая к демонтажу
- Демонтируемая котельная
- Существующая трансформаторная подстанция
- Существующая канализационная насосная станция
- Точка подключения к сетям водоснабжения
- Точка подключения к сетям водоотведения
- Точка присоединения к сетям теплоснабжения
- Точка подключения к сетям связи
- Точка подключения к сетям газоснабжения
- Точка подключения к сетям дождевой канализации
- Точка подключения к сетям электроснабжения

### Характеристика социально-бытового и культурного строительства

| Обозначение по генплану | Наименование | Единица измерения | Вместимость по проекту | Количество объектов | Площадь земельного участка (га) |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Общеобразовательные организации** | | | | |
| Ш-1 | Общеобразовательная школа ООШ №88 со строительством пристроя на 600 мест (реконструкция) | Мест | 1200 | 1 | 1,5 |